ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д. 3, с.Новый Кырлай,
Арский муниципальный район, 422035

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КЫРЛАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Үзәк урам, 3 йорт, Яңа Кырлай авылы,
Арча муниципаль районы, 422035

Тел. (84366)56-7-32, факс (84366)56-7-34. E-mail: Nkrl.Ars@tatar.ru

**КАРАР**

**«_10_» _ноябрь_ 2016 ел** **№ _24_**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңа Кырлай авыл җирлеге ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу планнарын формалаштыру, раслау һәм алып бару тәртибен раслау турында**

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 44-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1 өлеше, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Сатып алулар өлкәсендә нормалар билгеләү, күрсәтелгән актларны карап тоту һәм аларны үтәүне тәэмин итү турында хокукый актлар эшләү һәм кабул итү тәртибенә карата гомуми таләпләрне раслау турында» 2015 елның 18 маендагы 476 номерлы карары нигезендә Арча муниципаль районының Яңа Кырлай авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңа Кырлай авыл җирлеге ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуның план-графигын формалаштыру, раслау һәм алып бару тәртибен расларга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталындагы бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru/.

Яңа Кырлай авыл җирлеге башлыгы Г.Г.Сәфәров

Арча муниципаль районы
Яңа Кырлай авыл җирлеге
Башкарма комитетының
10.11.2016 ел, №24
карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр закупкаларының планын булдыру, раслау һәм алып бару тәртибе**

1. Әлеге Тәртип «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - контракт системасы турында) нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңа Кырлай авыл җирлегенең муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар планнарын (алга таба - сатып алулар планы) формалаштыру, раслау һәм алып бару кагыйдәләрен билгели.

2. Сатып алулар планнары эш көннәрендә саналган 10 көн эчендә расланa:

а) муниципаль берәмлек исеменнән гамәлдә булган муниципаль заказчылар (алга таба - муниципаль заказчылар) - тиешле муниципаль заказчыга Россия Федерациясенең бюджет законнары нигезендә йөкләмәләрне кабул итүгә һәм (яисә) үтәүгә акчалата чагылыш табуда хокуклар күләмен җиткергәннән соң;

б) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңа Кырлай авыл җирлеге муниципаль бюджет учреждениеләре тарафыннан, контракт системасы турында Законның 15 статьясындагы 2 һәм 6 өлешләре нигезендә гамәлгә ашырыла торган сатып алулардан тыш, - финанс-хуҗалык эшчәнлеге планнарын раслаганнан соң;

3. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңа Кырлай авыл җирлеге ихтыяҗларын тәэмин итү өчен закупкалар планнары әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән затлар тарафыннан Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә региональ мәгълүмат системасыннан файдаланып, чираттагы финанс елына һәм план чорына (чираттагы финанс елына) түбәндәге нигезләмәләрне исәпкә алып төзелә:

- әмма агымдагы елның 1 июленнән дә соңга калмыйча:

1) контракт системасы турында Законның 13 статьясы нигезләмәләрен исәпкә алып билгеләнгән сатып алуларны гамәлгә ашыру максатларыннан чыгып сатып алулар планнарын төзиләр һәм аларны сатып алуларны гамәлгә ашыруга бюджет ассигнованиеләренең Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә аларны формалаштыру өчен төп күрсәтмәчеләргә тапшыралар;

2) бюджет сметалары проектларын төзү барышында сатып алуларның төп күрсәтмә бирүчеләре белән килештереп, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңа Кырлай авыл җирлеге бюджеты турында закон проектын төзегәндә, Россия Федерациясенең бюджет законнары нигезендә сатып алуларны гамәлгә ашыруга бюджет ассигнованиеләренең нигезләмәләрен төп күрсәтмә бирүчеләр тарафыннан тәкъдимнәр кертәләр;

3) кирәк булганда сатып алуларның формалашкан планнарын төгәллләштерәләр, аларны төгәлләштергәннән һәм муниципаль заказчыга кабул итүгә һәм (яисә) йөкләмәләрне үтәүгә хокуклар күләмен акчалата чагылышта җиткергәннән соң, әлеге Тәртипнең 2 пунктында билгеләнгән срокларда, сатып алуларның планнары төзелгән һәм бу хакта баш күрсәтмә бирүчегә хәбәр итәләр;

4) әлеге Тәртипнең 2 пунктының «б» пунктчасында күрсәтелгән учреждениеләр, аларны гамәлгә куючының функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы органнар

билгеләгән срокларда, әмма бу елның 1 июленнән дә соңга калмыйча:

Россия Федерациясе законнары нигезендә финанс-хуҗалык эшчәнлеген планлаштырганда сатып алулар планнарын төзиләр һәм аларны гамәлгә куючының функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы органнарга бюджет ассигнованиеләренең нигезләмәләрен Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә төзегәндә исәпкә алу өчен тапшыралар;

кирәк булганда, аларны гамәлгә куючының функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы органнар белән килештереп, аларны финанс-хуҗалык эшчәнлеге планнары проектларын төзү һәм бюджет ассигнованиеләренең Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә тәкъдимнәрен тапшыру барышында сатып алулар планына төзәтмәләр кертәләр;

кирәк булганда сатып алуларның планнарын тәгәлләштерәләр, аларны тәгәлләштергәннән һәм финанс-хуҗалык эшчәнлеге планнарын раслаганнан соң әлеге Тәртипнең 2 пунктында билгеләнгән срокларда, сатып алуларның формалашкан планнарын раслыйлар һәм бу хакта аларны гамәлгә куючының функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы органга хәбәр итәләр;

4. Чираттагы финанс елына һәм план чорына сатып алулар планы сатып алуларның расланган планы һәм аларга план чорының икенче ел параметрларын өстәү юлы белән эшләнә.

5. Сатып алулар планнары Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңа Кырлай  авыл җирлеге бюджеты төзелә торган вакытка формалаштырыла.

6. Муниципаль заказчыларны Россия Федерациясенең бюджет законнары нигезендә сатып алулар планына, шулай ук әлеге Тәртипнең «б» һәм 2 пункты бүлекләрендә күрсәтелгән юридик затларны сатып алу планнарына план чоры узганнан соң гамәлгә ашырылуы планлаштырылган сатып алулар турында мәгълүмат кертелә. Бу очракта мәгълүмат планлаштырылган сатып алуларның бөтен вакытына сатып алулар планнарына кертелә.

7. Әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән затлар сатып алуларның планнарын контракт системасы турындагы закон һәм әлеге Тәртип нигезләмәләре нигезендә алып баралар. Кирәк очракта сатып алуларның расланган планнарына үзгәрешләр кертү өчен түбәндәгеләр нигез була:

а) контракт системасы турында Законның 13 статьясы нигезләмәләрен һәм сатып алына торган товарларга, эшләргә, хезмәт күрсәтүләргә (шул исәптән товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең иң чик бәяләре) таләпләр контракт системасы турында Законның 19 статьясы нигезендә билгеләнгән һәм дәүләт органнары һәм аларга буйсынучы казна учреждениеләре, территориаль бюджеттан тыш дәүләт фондлары белән идарә органнары функцияләрен тәэмин итүгә норматив чыгымнар нигезендә билгеләнгән сатып алулар планнарын расланган үзгәрешләргә туры китерү;

б) агымдагы финанс елына (агымдагы финанс елына һәм план чорына) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңа Кырлай  авыл җирлеге бюджетына үзгәрешләр кертү турындагы карарга закупкалар планнарын туры китерү;

в) сатып алулар планнарын раслаганнан соң кабул ителгән һәм Татарстан Республикасы бюджеты турында закон белән расланган бюджет ассигнованиеләре күләмен үзгәртүгә китермәгән федераль законнарны, карарларны, йөкләмәләрне, Россия Федерациясе Президентының, Татарстан Республикасы законнарының карарларын, йөкләмәләрен, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларын, йөкләмәләрен гамәлгә ашыру;

г) сатып алуларның мәҗбүри иҗтимагый фикер алышуы йомгаклары буенча муниципаль заказчы яисә юридик зат тарафыннан кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру;

д) сатып алулар башкарганда алынган экономиядән Россия Федерациясе законнары нигезендә файдалану;

е) контракт системасы турындагы законның 99 статьясында билгеләнгән контроль органнары тарафыннан күрсәтмә бирү, шул исәптән тәэмин итүчеләрне (подрядчыларны, башкаручыларны) билгеләү процедурасын гамәлдән чыгару турында.

8. Сатып алулар планына аларны гамәлгә ашыру турында хәбәр итү йә җиткерүчене

(башкаручыны) билгеләүдә катнашу планлаштырыла торган сатып алулар турында мәгълүмат, шулай ук контракт системасы турындагы Законда билгеләнгән очракларда чираттагы финанс елында һәм (яисә) план чорында җибәрү планлаштырыла торган сатып алулар турында мәгълүмат, шулай ук контракт күрсәтелгән вакыт дәвамында төзелергә планлаштырыла торган бердән-бер тәэмин итүчедән (подрядчыдан, башкаручыдан) сатып алулар турында мәгълүмат кертелә.

9. Мондый планны раслаган яисә үзгәрткән көннән алып эш көннәрендә санала торган сатып алуларның расланган планы, дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрдән тыш, бердәм мәгълүмат системасында РИС кулланып урнаштырыла.

10. Сатып алулар планы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 21 ноябрендәге 1043 номерлы “Россия Федерациясе субъекты ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар планнарын формалаштыруга, раслауга һәм алып баруга таләпләр, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәтләр закупкалары планы формасына таләпләр турында” карары белән расланган рәвештә формалаштырыла.